**СОВЕТ БЕРЕЗКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422712, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Березка, ул. Новостройка, 15А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЕНЛЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422712, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Каеноык авылы, Новостройка урамы, 15А

Тел./факс 8(84365) 79-2-08, e-mail:Berez.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**15 гыйнвар 2021 г.** **№ 17**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уставын туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 34 нче номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына (Советның 07.08.2020 № 50 карары редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 16 һәм 17 пунктлар белән тулыландырырга:

«16) участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфаны хезмәткәр биләгән чорга торак урыны бирү;

17) алкогольле, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.»;

2) 11 статьяда түбәндәге эчтәлекле 11.1) пункт белән тулыландырырга:

«11.1) инициатив проектлар;»;

3. 17 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 8.1 өлеш белән тулыландырырга:

«8.1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары проект инициаторлары буларак инициатив проектны тәкъдим итәргә мөмкин.».

б) 17 статьяның 9 өлешен түбәндәге эчтәлекле 7 пункт белән тулыландырырга:

«7) инициатив проектны буенча фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.»;

4) 20 статьяның 6 өлешен түбәндәге эчтәлекле 4.1 пункт белән тулыландырырга:

«4.1) Авыл торак пунктында яшәүчеләр өчен өстенлекле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча инициатив проект кертү инициативасы белән чыгыш ясарга хокуклы;»;

5) 22 статьяның 1 өлешендә «һәм Җирлекнең җирле үзидарәсе вазыйфаи затлары,» сүзләреннән соң «инициатив проектлар кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча фикер алышу,» сүзләрен өстәргә;

6) 25 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Гражданнарны сораштыруда сайлау хокукына ия муниципаль берәмлек халкы катнашырга хокуклы. Гражданнарның инициатив проектны яклау турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча сораштыруда инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән муниципаль берәмлек яисә аның өлешенең уналты яшькә җиткән халкы катнашырга хокуклы.»;

б) 3 өлешне түбәндәге эчтәлекле 3) пункт белән тулыландырырга:

«3) инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган җирлектә яисә аның өлешләрендә уналты яшькә җиткән яшәүчеләрнең - әлеге инициатив проектны яклау турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен.»;

в) 25 статьядагы 5 өлешнең 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гражданнарны сораштыру билгеләү турындагы карар Җирлек Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнардан сораштыруны үткәрү өчен Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты кулланылырга мөмкин. Гражданнарны сораштыруны билгеләү турында Җирлек Советының норматив хокукый актында билгеләнә:»;

г) 25 статьяның 5 өлешен түбәндәге эчтәлекле 6 пункт белән тулыландырырга:

«6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтыннан файдаланып гражданнарны сораштыру үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.»;

д) 25 статьядагы 7 өлешнең 1 пунктын «яки муниципаль берәмлек халкының» сүзләре белән тулыландырырга;

7) түбәндәге эчтәлекле 25.1 статья белән тулыландырырга:

«25.1 статья. Инициатив проектлар

1. Җирлектә яшәүчеләр яисә аның өлеше өчен өстенлекле әһәмияткә ия чараларны гамәлгә ашыру максатларында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне яисә җирле үзидарә органнарына бирелгән башка мәсьәләләрне хәл итү буенча җирлекнең Башкарма комитетына инициатив проект кертелергә мөмкин. Инициатив проектлар гамәлгә ашырыла ала торган җирлек территориясенең бер өлешен билгеләү тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

2. Инициатив проектны кертү инициативасы белән уналты яшькә җиткән һәм җирлек территориясендә яшәүче кимендә ун граждан, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, авыл торак пункты старостасы (алга таба - проект инициаторлары) инициатив төркем чыгыш ясарга хокуклы. Инициатив төркемнең минималь саны җирлек Советының норматив хокукый акты белән киметелергә мөмкин. Проект инициаторы буларак чыгыш ясау хокукы җирлек Советының норматив хокукый акты нигезендә шулай ук тиешле җирлек территориясендә эшчәнлек алып баручы башка затларга да бирелергә мөмкин.

3. Инициатив проектта түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) җирлек халкы яисә аның өлеше өчен өстенлекле әһәмияткә ия проблеманы тасвирлау;

2) күрсәтелгән проблеманы хәл итү буенча тәкъдимнәрне нигезләү;

3) инициатив проектны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәсен (көтелгән нәтиҗәләрен) тасвирлау;

4) инициатив проектны гамәлгә ашыруга кирәкле чыгымнарның якынча хисабы;

5) инициатив проектны гамәлгә ашыруның планлаштырыла торган сроклары;

6) әлеге проектны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның планлаштырган (мөмкин булган) финанс, мөлкәт һәм (яисә) хезмәт белән катнашуы турында белешмәләр;

7) инициатив түләүләрнең планлаштырылган күләменнән тыш, әлеге акчаларны инициатив проектны гамәлгә ашыруга куллану күздә тотылган очракта, җирле бюджет акчалары күләменә күрсәтү;

8) чикләрендә инициатив проект гамәлгә ашырылачак җирлек яисә аның өлеше территориясенә җирлек Советының норматив хокукый актында билгеләнгән тәртип нигезендә күрсәтү;

9) җирлек Советының норматив хокукый актында каралган башка белешмәләр.

4. Инициатив проект, аны җирлек Башкарма комитетына кертkәнче, инициатив проект буенча фикер алышу, җирлек яисә аның өлеше халкының мәнфәгатьләренә туры килүен, инициатив проектны гамәлгә ашыруның максатка ярашлылыгын билгеләү, шулай ук инициатив проектны хуплау турында гражданнарның җыенында, җыелышында яисә конференциясендә карар кабул итү максатларында гражданнар җыенында, җыелышында яисә конференциясендә, шул исәптән территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында яисә конференциясендә каралырга тиеш. Шул ук вакытта гражданнарның бер җыенында, бер җыелышында яисә бер конференциясендә берничә инициативалы проект каралырга мөмкин.

Җирлек Советының норматив хокукый акты белән инициатив проектны яклау мәсьәләсе буенча гражданнарның фикерләрен ачыклау мөмкинлеге шулай ук гражданнарны сораштыру, аларның имзаларын җыю юлы белән каралырга мөмкин.

Проект инициаторлары инициатив проектны җирлек Башкарма комитетына керткәндә, инициатив проектын җирлек яисә аның өлеше халкы яклавын раслый гражданнар җыены, җыелышы яисә конференциясенең беркетмәсен, гражданнарны сораштыру нәтиҗәләрен һәм (яисә) имза кәгазьләрен кушалар.

5. Инициатив проектны җирлек Башкарма комитетына кертү турындагы мәгълүмат инициатив проект җирлек Башкарма комитетына кертелгән көннән алып өч эш көне эчендә җирлекнең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә басылып чыгарга (халыкка җиткерергә) һәм урнаштырылырга тиеш һәм әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне, шулай ук проектның инициаторлары турында белешмәләр булырга тиеш. Бер үк вакытта гражданнар җирлек Башкарма комитетына үзләренең тәкъдимнәрен һәм кисәтүләрен, аларны тәкъдим итү срогын күрсәтеп, ә ул биш эш көненнән дә ким була алмый, тәкъдим итү мөмкинлеге турында хәбәр ителә. Үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен уналты яшькә җиткән җирлек халкы җибәрергә хокуклы. Җирлекнең Башкарма комитеты күрсәтелгән мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, күрсәтелгән мәгълүмат Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла. Күрсәтелгән мәгълүматны гражданнар игътибарына авыл торак пунктының старостасы җиткерергә мөмкин.

6. Инициатив проект кертелгән көннән алып 30 көн эчендә җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш. Инициатив проектны карау нәтиҗәләре буенча җирлекнең Башкарма комитеты түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) инициатив проектны хупларга һәм аның өстендә эшне җирле бюджет турындагы карар белән каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә тиешле максатларга һәм (яисә) җирле бюджет проектын төзү һәм карау тәртибе (җирле бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү) нигезендә дәвам итәргә;

2) инициатив проектны хуплаудан баш тартырга һәм инициатив проектны хуплаудан баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, аны проект инициаторларына кайтарырга.

7. Җирлекнең Башкарма комитеты түбәндәге очракларның берсендә инициатив проектны хуплаудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) инициатив проектны кертүнең һәм аны карауның билгеләнгән тәртибен үтәмәү;

2) инициатив проектның федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары таләпләренә, Россия Федерациясе субъектларының законнарына һәм башка норматив хокукый актларына, җирлек уставына туры килмәве;

3) җирле үзидарә органнарының кирәкле вәкаләтләре һәм хокуклары булмаганлыктан, инициатив проектны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмау;

4) инициатив түләүләре аларны барлыкка китерү чыганагы булмаган инициатив проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләмендә җирле бюджет акчалары булмау;

5) инициатив проектта тасвирланган проблеманы нәтиҗәлерәк хәл итү мөмкинлеге булу;

6) инициатив проектны конкурс сайлавын узмаган дип тану.

8. Җирлекнең Башкарма комитеты проект инициаторларына бергәләп инициатив проектны эшләп бетерергә тәкъдим итәргә, шулай ук аны башка җирлекнең җирле үзидарә органы яисә дәүләт органы каравына аларның

компетенцияләре нигезендә тәкъдим итәргә хокуклы, ә әлеге статьяның 7 пунктының 5 пунктчасында каралган очракта тиеш.

9. Инициатив проектларны күрсәтү, кертү, тикшерү, карау, шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибе җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.

10. Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән финанс ярдәме алу өчен тәкъдим ителә торган инициатив проектларга карата инициатив проектлар булырга тиешле белешмәләр составына таләпләр, инициатив проектларны карау тәртибе, шул исәптән аларны хуплаудан баш тарту өчен нигезләр, мондый инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибе һәм критерийлары закон һәм (яисә) Россия Федерациясе субъектының башка норматив хокукый акты нигезендә билгеләнә. Бу очракта әлеге статьяның 3, 6, 7, 8, 9, 11 һәм 12 пунктларындагы таләпләр кулланылмый.

11. Җирлекнең Башкарма комитетына берничә инициативалы проект кертелгән булса, шул исәптән эчтәлеге буенча шундый ук өстенлекле проблемаларны тасвирлап, җирлекнең Башкарма комитеты конкурс нигезендә сайлап алуны оештыра һәм бу хакта проектның инициаторларына хәбәр итә.

12. Инициатив проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү коллегиаль органга (комиссиягә) йөкләнә, аны төзү һәм эшчәнлек тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә. Коллегия органның (комиссиянең) составы җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан төзелә. Мондый чакта коллегиаль орган (комиссия) әгъзаларының гомуми санының яртысы җирлек Советы тәкъдимнәре нигезендә билгеләнергә тиеш. Проектның инициаторларына һәм аларның вәкилләренә конкурс нигезендә сайлап алуны уздырганда коллегиаль орган (комиссия) тарафыннан инициатив проектларны карауда катнашу һәм алар буенча үз позицияләрен бәян итү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

13. Проект инициаторлары, җирлек территориясендә яшәүче гражданнарның җыены, җыелышы яисә конференциясе тарафыннан вәкаләтләр бирелгән башка гражданнар, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган башка затлар инициатив проектны Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган рәвешләрдә гамәлгә ашыруны җәмәгать контролендә тотарга хокуклы.

14. Җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан инициатив проектны карау турында, инициатив проектны гамәлгә ашыру барышы турында, шул исәптән акчаларны куллану турында, аны гамәлгә ашыруда кызыксынучы затларның мөлкәти һәм (яисә) хезмәт катнашуы турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирлекнең рәсми сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш. Инициатив проектны гамәлгә ашыру йомгаклары турында җирлек Башкарма комитетының хисабы инициатив проектны гамәлгә ашыру тәмамланган көннән алып 30 календарь көн эчендә җирлекнең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм урнаштырылырга тиеш. Җирлекнең Башкарма комитеты күрсәтелгән мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру мөмкинлеге булмаган очракта, күрсәтелгән мәгълүмат Биектау муниципаль районының рәсми сайтында

урнаштырыла. Күрсәтелгән мәгълүматны гражданнарга авыл торак пунктының старостасы җиткерергә мөмкин.»;

8) 32 статьяның 4 өлешен түбәндәге эчтәлекле 2 абзац белән тулыландырырга:

«Үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыру өчен җирлек Советы депутатына эш урынын (вазыйфасын) аена 3 эш көнен тәшкил иткән чорга саклап калу гарантияләнә.»;

9) 51 статьяның 2 өлешен түбәндәге эчтәлекле 16 һәм 17 абзацлар белән тулыландырырга:

«участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфаны хезмәткәр биләгән чорга торак урыны бирү.

алкогольле, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру»;

10) 66 статьяның 4 пунктын төшереп калдырырга;

11) 85 статьядагы 8 пунктның 2 абзацын «Бухгалтерлык» сүзеннән соң «(финанс)» сүзе белән тулыландырырга;

12) 88 статьяның 3 өлеше үз көчен югалткан дип танырга;

2. Әлеге карарны кабул иткән көннән алып 15 (унбиш) көн эчендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге Башлыгына әлеге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә җибәрүне йөкләргә.

3. Әлеге карар дәүләт теркәве узганнан соң Татарстан Республикасы, Биектау районы, Каенлык авылы, Үзәк урамы, 12 йорт, Чыршы авылы, Үзәк урамы, 34А йорт, Шуман авылы, Үзәк урамы, 27 йорт, Өнсә авылы, Колхоз урамы, 7А йорт адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) мизгелдән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы И.И.Гатауллин